РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
Совет
Краснокадкинского сельского поселения
Нижнекамского муниципального района

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
Түбән Кама муниципаль районы
Кызыл Чапчак авыл җирлеге
Советы

423558, Нижнекамский район,
с. Верхние Челны, ул. Молодежная, 13

423558, Түбән Кама районы,
Югары Чаллы авылы, Яшьләр урамы, 13

тел./факс (8555) 44-50-21, электронный адрес: Krasnokadkin.sp@tatar.ru, сайт: www.krasnokadkinskoe-sp.ru

РЕШЕНИЕ

КАРАР

16.04.2021 ел

№ 4

Кызыл Чапчак авыл җирлеге Советының 2019 елның 20 декабрендәге 30 номерлы «Кызыл Чапчак авыл җирлеге бюджетыннан Түбән Кама муниципаль районы бюджетына башка бюджетара трансфертлар бирү тәртибен раслау турында» карарына үзгәрешләр кертү турында

Россия Федерациясе Бюджет кодексының 9, 142.3, 142.5 статьялары, Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы «Кызыл Чапчак авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 31 статьясы нигезендә, Кызыл Чапчак авыл җирлеге Советы карар бирә:

1. Кызыл Чапчак авыл җирлеге Советының 2019 елның 20 декабрендәге 30 номерлы «Кызыл Чапчак авыл җирлеге бюджетыннан Түбән Кама муниципаль районы бюджетына башка бюджетара трансфертлар бирү тәртибен раслау турында» карарына (алга таба – карар) түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1.1 Карарның исемендә «Кызыл Чапчак авыл җирлеге» сүзләреннән соң «субсидияләр һәм» сүзләрен өстәргә.

1.2 Карарның 1 пунктында «Кызыл Чапчак авыл җирлеге» сүзләреннән соң «субсидияләр һәм» сүзләрен өстәргә, «(кушымта)» сүзен «(1 нче кушымта)» сүзләренә алмаштырырга.

1.3 Карарны түбәндәге эчтәлекле 1.1 пунктча белән тулыландырырга:

«1.1 «Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Кызыл Чапчак авыл җирлеге бюджетыннан Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы бюджетына бирелә торган субсидияләр күләмен исәпләү методикасын расларга».

1.4 Карар белән расланган Кызыл Чапчак авыл җирлеге бюджетыннан Түбән Кама муниципаль районы бюджетына башка бюджетара трансфертлар бирү тәртибендә:

нумерация исемендә «Кушымта» сүзен «1 нче кушымта» сүзләренә алмаштырырга;

исемендә «Кызыл Чапчак авыл җирлегенең» сүзләреннән соң «субсидияләр һәм» сүзләрен өстәргә;

1 бүлектә «Кызыл Чапчак авыл җирлегенең» сүзләреннән соң «субсидияләр һәм» сүзләрен өстәргә, «бирү» сүзен «субсидияләр һәм» сүзләреннән соң өстәргә;

2 бүлекнең 1 абзацында «башка бюджетара» сүзләрен «субсидияләр һәм башка бюджетара» сүзләренә алмаштырырга;

3 бүлекнең исемендә «бирү» сүзен «субсидияләр һәм» сүзләреннән соң өстәргә;

3 бүлекнең 1 пунктында «бюджетара трансфертлар» сүзләрен «субсидияләр һәм бюджетара трансфертлар» сүзләренә алмаштырырга;

3 бүлекнең 3 пунктында «бүлү» сүзен «субсидияләр һәм» сүзләреннән соң өстәргә;

3 бүлекнең 4 пунктында «бирү тәртибе» сүзләрен «субсидияләр һәм» сүзләреннән соң өстәргә;

3 бүлекнең 5 пунктында «бюджетара трансфертлар» сүзләрен «субсидияләр» сүзләренә алмаштырырга;

3 бүлекнең 6 пунктында «бюджетара трансфертлар бирү» сүзләрен «субсидияләр һәм бюджетара трансфертлар бирү» сүзләренә алмаштырырга;

3 бүлекнең 8 пунктында «бирүдә» сүзен «субсидияләр һәм» сүзләреннән соң өстәргә;

4 бүлекнең исемендә «файдаланудан» сүзен «субсидияләр һәм» сүзләреннән соң өстәргә;

4 бүлекнең 3 пунктындагы беренче җөмләдә «файдаланудан» сүзен «субсидияләр һәм» сүзләреннән соң өстәргә;

4 бүлекнең 4 пунктында «рәвешендә бирелгән» сүзләрен «субсидияләр һәм» сүзләреннән соң өстәргә;

4 бүлекнең 5 пунктында «максатсыз файдаланган өчен» сүзләрен «субсидияләр һәм» сүзләреннән соң өстәргә.

2. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Кызыл Чапчак авыл җирлеге
башлыгы Б.В. Ильдарханов

Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Кызыл Чапчак авыл җирлеге бюджетыннан Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы бюджетына җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча җирле үзидарә органнары вәкаләтләрен башкарганда барлыкка килә торган чыгым йөкләмәләрен финанслашу максатларында бирелә торган субсидияләр күләмен исәпләү методикасы

1. Кызыл Чапчак авыл җирлеге бюджетыннан Түбән Кама муниципаль районы бюджетына субсидияләр күләме, җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча җирле үзидарә органнары вәкаләтләрен башкарганда барлыкка килә торган чыгым йөкләмәләрен финанслашу максатларында, түбәндәге формула буенча билгеләнә:

S= (Д1+Д2) - (Р+С)

кайда:

S – Кызыл Чапчак авыл җирлеге бюджетыннан Түбән Кама муниципаль районы бюджетына бирелә торган субсидия күләме;

Д1 – Кызыл Чапчак авыл җирлегенең Россия Федерациясе Бюджет законнары, салымнар һәм җыемнар турындагы законнар һәм башка мәҗбүри түләүләр турындагы законнар нигезендә беркетелгән салым һәм салым булмаган керемнәре;

Д2 – Түбән Кама муниципаль районы бюджетыннан түләүсез керемнәр;

Р – Кызыл Чапчак авыл җирлеге бюджетының Түбән Кама муниципаль районының берләштерелгән бюджетын формалаштыруга бердәм төп алымнар нигезендә формалаштырылган җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә чыгымнары;

С – Россия Федерациясе субъекты бюджеты турында Россия Федерациясе субъекты законы нигезендә Кызыл Чапчак авыл җирлеге бюджетыннан Россия Федерациясе субъекты бюджетына күчерелергә тиешле субсидияләр.

2. Кызыл Чапчак авыл җирлеге бюджетыннан Түбән Кама муниципаль районы бюджетына җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча җирле үзидарә органнары вәкаләтләрен башкарганда барлыкка килә торган чыгым йөкләмәләрен финанслашу максатларында бирелә торган субсидияләрне исәпләү тәртибе

Субсидия күләме, Кызыл Чапчак авыл җирлеге чыгымнарын алганнан соң, Кызыл Чапчак авыл җирлеге кереме буларак исәпләнә.